**СОВЕТ МУЛЬМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422731, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Мульма, ул. Центральная, 46а

**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МҮЛМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422731, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Мүлмә авылы, Үзәк урамы, 46а

тел./факс 8(84365) 70-2-03, e-mail: Mulm.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**27 август 2024 ел** **№103**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлегендә бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының 2021 елның 24 сентябрендәге 37 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 23.07.02-08-01 номерлы протесты нигезендә, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлегендә бюджет процессы турында» 2021 елның 24 сентябрендәге 37 номерлы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Мүлмә авыл җирлегендә бюджет процессы турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль берәмлегендә (2021 елның 13 декабрендәге 41 номерлы, 2024 елның 19 февралендәге 88 номерлы карарларлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 9 статьяның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 14 пунктча өстәргә:

«14. «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында капиталь төзелеш объектлары һәм күчемсез мөлкәт объектлары турында белешмәләр төзи, аларга федераль бюджет акчалары (дәүләт оборона заказына кертелгән капиталь төзелеш объектларыннан һәм күчемсез мөлкәт объектларыннан тыш) капитал салуларны финанс белән тәэмин итү (финанслашу) чыганагы булып тора.».

2. Әлеге карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында: https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Совет председателе,
Мүлмә авыл җирлеге башлыгы Л.Р. Зиннәтуллин